ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

20.09.2019 г. Бугульма № 567

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 07 февралендә кабул иткән “Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпквартирлы йортны һәлакәт хәлендә, сүтәргә яки реконструкцияләргә кирәк дип, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга туры китерү максатында:

1. Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпквартирлы йортны һәлакәт хәлендә, сүтәргә яки реконструкцияләргә кирәк дип, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2нче бүлегенең 2.6нчы пунктының (алга таба – Административ регламент) стандартка таләпләр эчтәлеге өлешенә, 2.6нчы пунктны яңа басмада бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Ведомствоара багланышлар кысаларында алыналар:

1) Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан торак бинага хокуклар турындагы мәгълүматлар;

2) торак бина өчен – техник паспорт, ә торак булмаган бина өчен – техник план;

3) тиешле дәүләт күзәтчелеге (контроль) органнарының йомгаклары (актлары), әгәр дә йомгаклау актларын бирү торак бинаны Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә яраклы (яраклы түгел) түгел дип тану турында карар кабул итү өчен кирәк булса;

4) физик зат турында Россия Федерациясе законнары тарафыннан каралган идентификатор, әгәр дә документлар һәм мәгълүматлар физик затка мөнәсәбәттә соралса.».

2. Административ регламентның 2нче бүлегенең 2.4нче пунктының стандартка таләпләр эчтәлеге өлешенә караган “яки дәүләт күзәтчелеге

(контроле) органы йомгагы” сүзләрен “, яки дәүләт күзәтчелеге (контроле) органы йомгагы, яки, РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварында кабул ителгән “Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпквартирлы йортны һәлакәт хәлендә, сүтәргә яки реконструкцияләргә кирәк дип, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау турында”гы 47нче карарның 42нче пунктында каралганча, торак бинаның экспертиза йомгагы” дигән сүзләр белән алыштырырга.

3. Административ регламентның 5нче бүлегенең 5.8нче пунктын яңа басмада бәян итәргә:

«5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, сораучы-мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 5.7нче пунктының 3нче абзацында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә юл куелган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган, күпфункцияле үзәк яки 2010 елның 27 сентябрендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы №210-ФЗ Федераль законы тарафыннан каралган оешманың гамәлләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук кыенлыклар тудырган өчен гафу үтенелә, сораучы-мөрәҗәгать итүчегә алга таба ни эшләргә кирәклеге турында информация бирелә.».

4. Карар текстының башка өлешен үзгәрешсез калдырырга.

5. Әлеге карар күмәк мәгълүмат чараларында рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Башкарма комитет җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы В.В. Гарәфетдинов